КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 20 март г.Казань № 292

2023 елда сатулар үткәрмичә сатыла торган Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләре яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре өчен бәя билгеләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 һәм 2023 елларда Россия Федерациясендә җир мөнәсәбәтләрен җайга салу үзенчәлекләре турында» 2022 елның 9 апрелендәге 629 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының $39^4$ статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 һәм 2023 елларда Россия Федерациясендә җир мөнәсәбәтләрен җайга салу үзенчәлекләре турында» 2022 елның 9 апрелендәге 629 номерлы карарының 1 пунктындагы «а» пунктчасында каралган очракларда Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләренә яки дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләренә карата торглар үткәрмичә җир кишәрлеген сату-сатып алу шартнамәсен төзегәндә җир кишәрлегенең бәясе гражданның яки юридик затның мондый җир кишәрлеген бирү турындагы мөрәҗәгате кергән вакытта гамәлдә булган җир кишәрлегенең кадастр кыйммәте күләмендә билгеләнә дип билгеләргә.

2. Бу карарның гамәле 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

2. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалта.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин